КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 июнь г.Казань № 497

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 май, 374 нче, 2020 ел, 17 май, 398 нче, 2020 ел, 23 май, 420 нче, 2020 ел, 03 июнь, 465 нче, 2020 ел, 06 июнь, 471 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу шартларында профилактик чараларны үтәүне тәэмин итә торган формада чаралар оештыру һәм үткәрү рөхсәт ителә.»;

7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр Татарстан Республикасына 2020 елның 18 июненнән чит дәүләтләр территорияләреннән килгән (кайткан) гражданнарнга, шулай ук изоляцияне тәэмин итү чорында күрсәтелгән затлар белән

бергә яшәүче гражданнарга яшәү (тору) урыны буенча 14 календарь көн эчендә үзизоляцияләүне тәэмин итүне йөкләргә.».

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карар, әлеге карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацыннан тыш, 2020 елның 18 июненнән үз көченә керә;

әлеге карарның 1 пунктындагы дүртенче абзац 2020 елның 22 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин